# КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘ

1) **Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.**
2) **Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.**
3) **Бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.**
4) **Берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә**

# ТИҢДӘШ ИЯРҮЛЕ КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘ

**Бу төр кушма җөмләләрдә берничә иярчен җөмлә бер баш җөмләгә буйсынып килә, һәм алар барысы да бер үк вазифаны (бер үк сорау, бер үк бәйләүче чара) башкара.**

1)Тимергалиев синоптиклардан сорашып белде: 2) ел яңгырлы киләчәк, 3) кояшлы көннәр аз булыр.

[ ] : ( ), ( ).

1) Балалар аякка баскач, 2) Фәрит үзе дә гаилә корып җибәргәч, 3) әнисе акчадан бөтенләй баш тартты.

(-кач), (-гәч), [ ].

# ТИҢДӘШ ТҮГЕЛ ИЯРҮЛЕ КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘ

**Бу төр кушма җөмләләрдә берничә иярчен җөмлә бер баш җөмләгә буйсынып килә, ләкин алар төрле вазифа (төрле сорау, төрле бәйләүче чара) башкара.**

1)Күңелендә ни үкенечләр бул**са да**, 2) яше арта барган **саен**, 3) кеше тыныч тормышка омтылып яши башлый.

( -са да ), ( саен ), [ ].

1) Давыл уз**ганда**, 2) бала базда булып калгандыр, күрәсең, 3)**чөнки** аның өсте ачык иде.

(-ганда), [ ], (чөнки),

# БЕР-БЕР АРТЛЫ ИЯРҮЛЕ КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘ

**Бу төр кушма җөмләләрдә бер җөмлә – икенчесенә, икенчесе өченчесенә һ.б. ияреп килә, һәм компонентлар арасында бер-бер артлы ияру урнаша.**

1)Сугыш бет**еп**, 2) бер ел үт**кәч** кенә, 3) әтиебез өйгә кайтып җитә.

( -еп ), ( -кәч ), [ ].

1) Тагын бер яңалык ишетте ул: 2) завод-фабрикалар туктa**у сәбәпле,** 3) эшсез калучыларга хөкүмәт хезмәт биржалары оештырган.

[ ] : (-у сәбәпле), ( ).

# БЕРНИЧӘ ТӨР ИЯРҮЛЕ КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘ

**Бу төр кушма җөмләләрдә бер баш җөмләгә ким дигәндә өч иярчен җөмлә иярә, алар арасында төрле ияру (тиңдәш, тиңдәш түгел, бер-бер артлы) бергә килә.**

1) Сугыш бет**еп**, 2) бер ел үт**кәч**, 3) авылга солдатлар инде кайтып бет**кәч,** 4) безнең әтиебезгә дә чират җитә.

( -еп ), ( -кәч ), ( -кәч ), [ ].

1) Тагын бер яңалык ишетте ул: 2) завод-фабрикалар туктау **сәбәпле,** 3) эшсез калучылар бик күбәйгән, 4) хөкүмәт хезмәт биржалары оештырырга мәҗбүр булган.

[ ] : (-у сәбәпле), ( ), ( ).

# КАЙСЫ АРТЫК?

1. а)( -еп ), ( -кәч ), ( -кәч ), [ ]. б)( -еп ), ( -кәч ), [ ].
в) [ ] : (-у сәбәпле), ( ), ( ).
2. а) [ ] : ( ), ( ). б)( -кәч ), ( -кәч ), [ ].
в) ( -еп ), ( -кәч ), [ ].
3. а) ( -са да ), ( саен ), [ ]. б) ( -са да ), ( -са ), [ ].
в) ( -са да ), [ ], ( -са да).